**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР
от 06.08.2021

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПР-164

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2020-2021 уку елына балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән мәктәп автобус маршрутларын ачу турында"

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларыннан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 03 августындагы 400 нче номерлы карарын үтәү йөзеннән, балаларны йөртү өчен кулланыла торган автобуслар белән укучыларны йөртүнең иминлеген тәэмин итү максатларында, **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2021 елның 4 августындагы мәктәп автобусларының хәрәкәт итү маршрутларын тикшерү акты нигезендә, 2021 елның 1 сентябреннән түбәндәге автобус маршрутларын ачарга:

1.1. "Татар Суксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 1нче номерлы автобус маршруты;

1.2. «Актаныш 1 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципальара махсус 2 нче номерлы мәктәп маршруты (1 нче автобус);

1.3. «Актаныш 2 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципальара махсус 2 нче номерлы мәктәп маршруты (1 нче автобус);

1.4. "Актаныш 2 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 2 нче номерлы мәктәп маршруты (2 нче автобус);

1.5. "Актаныш 2 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе " муниципальара махсус 2 нче номерлы мәктәп маршруты (3 нче автобус);

1.6. "Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 3 нче номерлы мәктәп маршруты;

1.7. "Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 4 нче номерлы мәктәп маршруты;

1.8. "Актаныш 1 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 5 нче номерлы мәктәп маршруты (2 нче автобус);

1.9. "Югары Яхшый төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 6нчы номерлы мәктәп маршруты;

1.10. "Киров урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 7 нче номерлы мәктәп маршруты;

1.11. "Әтәс төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 8 нче номерлы мәктәп маршруты;

1.12. "Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 9 нчы номерлы мәктәп маршруты (1 нче автобус);

1.13. "Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 9 нчы номерлы мәктәп маршруты (2 нче автобус);

1.14. "Богады төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 10 нчы номерлы мәктәп маршруты;

1.15. "Сәфәр урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 11 нче номерлы мәктәп маршруты;

1.16. "Теләкәй төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 12 нче номерлы мәктәп маршруты;

1.17. "Байсар төп гомуми белем бирү мәктәбе - Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 13 нче номерлы мәктәп маршруты;

2. " Татавтодор" АҖ Минзәлә филиалының Актаныш ДРСУ башлыгына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә автомобиль юлларын, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны даими чистартуны оештырырга.

3. Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә автомобиль юлларын, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны даими чистартуны оештырырга.

4. "Актаныш АТХ" МУП директорына тәкъдим итәргә:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МКУ белән килештерелгән автобус маршрутлары паспортларын һәм автобуслар хәрәкәте расписаниесен эшләргә һәм раслауга тапшырырга;

- мәктәп маршрутларын тикшерүнең рәсмиләштерелгән актларын тикшерү тәмамланганнан соң биш көн эчендә Башкарма комитет җитәкчесенә тапшырырга;

- расланган расписание нигезендә мәктәп автобусларын эксплуатациялəүне катгый тәэмин итү;

- инструктаж мәҗбүри үткәрелеп, кимендә 3 ел эш стажы булган машина йөртүчеләрне сайлап алуны тәэмин итәргә;

- мәктәп автобусларын эксплуатацияләү өчен җаваплы башкаручыларны билгеләү буенча боерык чыгарырга.

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча ЮХИДИ бүлеге башлыгына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры китереп, күрсәтелгән маршрутлар буенча мәктәп автобусларының куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча катгый контроль оештырырга.

6. Гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына:

- балаларны торак пунктлардан база мәктәбенә кадәр алып бару һәм кире кайтару өчен, балаларның исемлеген күрсәтеп, җаваплы укытучыларны (озатып йөрүче) билгеләргә. Ай саен озатып йөрүче укытучылар һәм укучылар белән мәҗбүри инструктажлар үткәрергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълумати рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

8. Башкарма комитет җитәкчесенең 2020 елның 29 августында кабул ителгән "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән мәктәп автобус маршрутларын ачу турында" ПР-158 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Р.М.Шакировага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И. Габдулхаев